ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2024ел № 8134

«2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасын раслау турында

Яшьләргә патриотик тәрбия бирү системасын алга таба үстерү һәм камилләштерү, дәүләт сәясәтенә рәсми кабул ителгән карашлар җыелмасын чагылдыра торган системалы алымны һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү өлкәсендәге эшчәнлекнең төп юнәлешләрен эшләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү концепциясен раслау турында» 2014 елның 16 сентябрендәге 666 номерлы Карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, шәһәр Уставының 53 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрен муниципаль берәмлегендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасында каралган чараларны финанслауны 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына, 2025 елга – 213,8 мең сум; 2026 елга – 213,8 мең сум; 2027 елга – 213,8 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2024 елның 5 декабрендәге
8134 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек. «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасының паспорты

| Программаның исеме | «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, датасы, номеры) | - Россия Федерациясе Конституциясе;<br>- «Россия Федерациясе Дәүләт флагы турында» 2000 елның 25 декабрендәге 1-ФКЗ номерлы Федераль конституцион закон;<br>- «Россия Федерациясе Дәүләт гербы турында» 2000 елның 25 декабрендәге 2-ФКЗ номерлы Федераль конституцион закон;<br>- Россия Федерациясенең «Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү турында» 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-1 номерлы Законы;<br>- «Россиянең хәрби дан һәм истәлекле даталары турында» 1995 елның 13 мартындагы 32-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында совет халкының Җиңүен мәңгеләштерү турында» 1995 елның 19 маендагы 80-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 31 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы;<br>- Россия Федерациясе Президентының «Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту буенча дәүләт сәясәте нигезләрен раслау турында» 2022 елның 9 ноябрендәге 809 номерлы Указы;<br>- Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең тышкы сәясәт концепциясен раслау турында» 2023 елның 31 мартындагы 229 номерлы Указы;<br>- Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби патриотик яшьләр һәм балалар берләшмәләре турында» 2000 елның 24 июлендәге 551 номерлы Карары;<br>- Россия Федерациясе гражданнарын патриотик тәрбияләү концепциясе (хәрби хезмәткәрләрнең, хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль мәсьәләләре буенча Хөкүмәт комиссиясе утырышында хупланды |

<table>
<tr><td></td><td>(2003 елның 21 маендагы 2(12)-П4 номерлы беркетмә));<br>- Татарстан Республикасы Конституциясе;<br>- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Законы;<br>- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында гражданнарны патриотик тәрбияләү турында» 2023 елның 9 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Законы;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү концепциясен раслау турында» 2014 елның 16 сентябрендәге 666 номерлы Карары;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы Карары.</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүчеләр</td><td>Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе</td></tr>
<tr><td>Программаны башкаручылар</td><td>Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе;<br>Башкарма комитетның мәгариф идарәсе;<br>Башкарма комитетның мәдәният идарәсе;<br>Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе;<br>Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе.</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты</td><td>Яшь буында рухи-әхлакый кыйммәтләр, гражданлык тәңгәллеге, конституцион һәм хәрби бурычка тугрылык формалаштыру.</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары:</td><td>1. Яр Чаллы шәһәрендә патриотик тәрбия системасын үстерү, яшьләрне Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәткә әзерләүне камилләштерү, яшьләргә хәрби-һөнәри юнәлеш бирү.<br>2. Яшьләрдә законнарны үтәү, Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә хөрмәт; Ватанга хезмәт итүгә, аны саклауга, гражданлык, һөнәри һәм хәрби бурычны намуслы үтәүгә әзерлек формалаштыру.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2025-2027 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="7">Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td>
<table>
<tr><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2025 ел (мең сум)</td><td>2026 ел (мең сум)</td><td>2027 ел (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>213,8</td><td>213,8</td><td>213,8</td><td>641,4</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>213,8</td><td>213,8</td><td>213,8</td><td>641,4</td></tr>
</table>
</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 2027 елга программаны тормышка ашыру хисабына түбәндәгеләр көтелә:<br>1. Программа чараларына җәлеп ителгән 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшьләр өлеше әлеге яшь төркеменең гомуми саныннан кимендә 5% ка арту.<br>2. Патриотик тәрбия өлкәсендә чараларны тормышка ашыру мәсьәләләре буенча патриотик юнәлешле иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек итү өчен шартлар тудыру – кимендә ел саен үткәрелә торган 12 уртак шәһәр патриотик чарасы.<br>3. Узган ел белән чагыштырганда ел саен кимендә 3% ка арттырып, яшьләр өчен патриотик проектларны һәм чараларны тормышка ашыруны тәэмин итү.<br>4. Патриотик юнәлешле оешмалар (берләшмәләр) (эзләү отрядлары, хәрби-патриотик, волонтерлык һәм башкалар) эшчәнлегендә катнаша торган 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшьләр өлеше арту. |
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Программа үтәлешенә гомуми контрольне Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе гамәлгә ашыра. |

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысулы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

«2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив-хокукый базасын, мәгариф, яшьләр сәясәте, мәдәният, физик культура һәм спорт өлкәсендә закон чыгару һәм башка норматив актларны исәпкә алып эшләнде.

Программа Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче балаларга һәм яшьләргә юнәлдерелгән. Программа нигезенә җирле үзидарә органнарының, мәгариф учреждениеләренең һәм патриотик һәм хәрби-патриотик юнәлешле иҗтимагый оешмаларның тәкъдимнәре кертелде.

Программаның актуальлеге балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү өлкәсен алга таба үстерү һәм киңәйтү ихтыяҗы, төп юнәлешләрне тормышка ашыру һәм патриотик эш тәҗрибәсен системалаштыру буенча маршрутизация булдыру зарурлыгы белән бәйле.

Программа патриотик тәрбия өлкәсендәге төп бурычларны хәл итүне тәэмин итәргә тиешле хокукый, оештыру һәм методик чаралар комплексыннан гыйбарәт һәм ул Яр Чаллы шәһәрендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион совет төзү аша җирле үзидарә органнарының, дәүләт хакимияте органнарының, белем бирү учреждениеләренең һәм иҗтимагый оешмаларның үзара хезмәттәшлеге ярдәмендә тормышка ашырылачак.

Заманча чынбарлык каршылыклары, яшьләргә үз иленә һәм аның мәнфәгатьләренә тугрылыклы граждан кыйммәтләрен формалаштыруның идея һәм идеологик нигезен тәэмин итәргә өнди торган патриотик тәрбия бирү ягыннан оператив һәм адекват тәэсир итүне таләп итә.

Шуңа бәйле рәвештә системалы эш түбәндәгеләргә караган чараларга юнәлдереләчәк:

- югары рухи-әхлакый принциплар һәм гражданлык җаваплылыгы, үз Ватанына мәхәббәт һәм тугрылык, җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакарь хезмәт итүгә,

шәһәрне үстерү планнарын гамәлгә ашыруда актив катнашуга әзерлек тәрбияләү;

- мәдәни-тарихи кыйммәтләр нигезендә яшьләрнең патриотик хисен һәм аңын формалаштыру;

- Ватаныбызның күп гасырлык тарихын, дөньякүләм тарихи процесста Россиянең урынын һәм ролен, илебез бәйсезлеге һәм мөстәкыйльлеге өчен көрәшкән төрле буынның героик үткәнен өйрәнү;

- конституцион, гражданлык һәм хәрби бурычны тирән аңлауны формалаштыру, мәдәниятне һәм белемле булуны югары үстерү;

- Ватанга лаеклы хезмәт итүгә әзерлек чагыла торган идеяне аңлау;

- үз-үзеңне тотуның югары әхлакый, һөнәри-этик нормаларын, фидакарьлек, җаваплылык һәм коллективизм, хөрмәт һәм хезмәткә намуслы мөнәсәбәт формалаштыру;

-тискәре социаль күренешләрне профилактикалау, яшьләр мохитендә сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру.

Соңгы елларда патриотик һәм әхлакый юнәлешле традицион шәһәр чаралары: «Җиңү көне», «Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне», «Җиңү тәрәзәсе», «Билгесез солдат көне», «Россия көне», «Республика көне», «Шәһәр көне» һәм шәһәр яшьләре актив катнаша торган башка акцияләр шәһәрнең иҗтимагый һәм мәдәни тормышының аерылгысыз өлеше булды.

## 3 бүлек. Тормышка ашыру срокларын күрсәтеп, программаның төп максаты, бурычлары

Программаны тормышка ашыру өч елга – 2025-2027 елларга исәпләнгән.

Программаның төп максаты булып яшь буында рухи-әхлакый кыйммәтләр, гражданлык тәңгәллеге, конституцион һәм хәрби бурычка тугрылык формалаштыру тора.

Күрсәтелгән максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Яр Чаллы шәһәрендә патриотик тәрбия системасын үстерү, яшьләрне Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәткә әзерләүне камилләштерү, яшьләргә хәрби-һөнәри юнәлеш бирү.

2. Яшьләрдә законнарны үтәү, Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә; Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының мәдәни тарихи үткәненә һәм традицияләренә хөрмәт, Ватанга хезмәт итүгә, аны саклауга, гражданлык, һөнәри һәм хәрби бурычны намуслы үтәүгә әзерлек формалаштыру.

## 4 бүлек. Программа чараларының системасы, исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

1. Патриотик тәрбия процессын камилләштерү буенча чаралар системасы түбәндәгеләрне күздә тота:

- хәзерге этапта патриотик тәрбия эшенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү;
- патриотик тәрбия эчтәлеген баету;
- патриотик тәрбиянең инновацион формаларын һәм ысулларын үстерү;
- Ватанны саклаганда һәлак булган сугышчыларны эзләү эше һәм аларның истәлеген мәңгеләштерү;
- җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакарь хезмәт итүгә, Ватанны саклау бурычларын үтәүгә әзерлек тәрбияләү;
- патриотик тәрбия процессы белән идарә итү системасын камилләштерү;
- Яр Чаллы шәһәрендә балаларда, яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә патриотик хисләр формалаштыру үзенчәлекләрен ачыклау максатында гуманитар һәм тәрбия программаларына экспертиза үткәрү;
- патриотик тәрбия өлкәсендә белгечләр әзерләү системасын камилләштерү;
- патриотик тәрбия системасында бара торган процессларны норматив-хокукый җайга салу юлы белән патриотик тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү.

2. Яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү.

Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча чаралар системасы түбәндәгеләргә юнәлдерелгән чараларны күздә тота:

- хәрби хезмәтнең абруен күтәрү;
- яшьләрне сәламәтләндерү, физик һәм психологик әзерләү;
- спортның хәрби-гамәли, спорт-техник төрләрен популярлаштыру;
- хәрби хезмәткә чакырылучыларның белем дәрәҗәсен күтәрү, алар тарафыннан хәрби-исәп белгечлекләре алу;
- гражданнарны хәрби хезмәт нигезләренә өйрәтү.

3. Патриотик юнәлешле иҗтимагый оешмаларның үсеше һәм аларга ярдәм күрсәтү.

Яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең төп база оешмалары булып «Юнармия» Бөтенроссия иҗтимагый хәрби-патриотик хәрәкәтенең Яр Чаллы штабы һәм «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләре үзәге» МБУ тора.

Яшьләр патриотик хәрәкәтен үстерү буенча чаралар системасы түбәндәгеләргә юнәлдерелгән чараларны күздә тота:

- хәрби-патриотик, патриотик хәрәкәтләрнең матди базасына ярдәм күрсәтү һәм камилләштерү;
- яшьләр өчен патриотик, хәрби-патриотик чараларны оештыруда һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтү;
- укучы һәм студент яшьләрне патриотик юнәлешле иҗтимагый оешмалар һәм хәрәкәтләр эшчәнлегенә җәлеп итү.

5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

| Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 1 нче ел (мең сум) | 2 нче ел (мең сум) | 3 нче ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| Муниципаль бюджет | 213,8 | 213,8 | 213,8 | 641,4 |
| Федераль бюджет | | | | |
| Республика бюджеты | | | | |

6 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирә торган индикаторлар

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү формуласы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Программа чараларына җәлеп ителгән 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшьләр өлеше әлеге яшь төркеменең гомуми санынннан:<br>2024 ел - 2 %<br>2025 ел - 3 %<br>2026 ел - 4 %<br>2027 ел - 5% | $C = \frac{C1 \times 100\%}{C2}$<br>монда C1 – программа чараларына җәлеп ителгән яшьләр саны;<br>C2 – Яр Чаллы шәһәре территориясендә яшәүче 14 яшьтән 35 яшькә | Квартал саен бирелә торган аналитик хисаплар:<br>Башкарма комитетның мәгариф идарәсе;<br>Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе;<br>Башкарма комитетның мәдәният идарәсе;<br>Башкарма комитетның физик культура һәм спорт |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | кадәрге яшьләрнең гомуми саны (хисап елына статистик мәгълүматлар буенча) | идарәсе (алга таба – идарәләр). |
| 2. | Тормышка ашырыла торган патриотик проектлар, чаралар саны. Программаны тормышка ашыру срогы дәвамында ел саен планлаштырылган күрсәткеч – узган ел белән чагыштырганда үсеш кимендә 3 %. | $J=\frac{(J2-J1)x100\%}{J1}$<br><br>монда J1 – узган ел дәвамында тормышка ашырыла торган патриотик проектлар саны;<br><br>J2 – хисап (агымдагы) елында тормышка ашырыла торган патриотик проектлар саны | Идарәләрнең үткәрелгән патриотик чаралар турында квартал саен бирелә торган аналитик хисаплары. |

7 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Патриотик тәрбия эше нәтиҗәлелегенең иң мөһим шарты булып, гомумиләштерелгән бәяләү күрсәткечләре нигезендә аның торышын даими анализлау тора.

Бу күрсәткечләр тулаем патриотик тәрбия торышын гына түгел, бу эшнең аерым якларын да билгеләргә мөмкинлек бирә.

Программаны тормышка ашыруның соңгы нәтиҗәсе буларак, Яр Чаллы шәһәрендә патриотизм үсешенең уңай динамикасы, гражданнарның, бигрәк тә яшьләрнең социаль һәм хезмәт активлыгы арту, аларның тормышның төп өлкәләрен, җәмгыять һәм дәүләт эшчәнлеген үстерүгә керткән өлеше, гражданнарның аерым төркемнәренең экстремистик чагылышларын һәм башка тискәре күренешләрне юкка чыгару, рухиятне торгызу, социаль-икътисадый һәм сәяси тотрыклылык һәм милли иминлекне ныгыту күздә тотыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасына
1 нче кушымта

«2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| № т/б | Төп чараның исеме | Башкаручылар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның зурлыгы | | | | Төп чараларны үтәү срогы | Финанслау күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 ел база | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | | 2024 ел база | 2025 ел мең сум | 2026 ел мең сум | 2027 ел мең сум |
| Программаның максаты: яшь буында рухи-әхлакый кыйммәтләр, гражданлык тәңгәллеге, конституцион һәм хәрби бурычка тугрылык формалаштыру. | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | | |
| 2026 елга программа буенча патриотик эшчәнлеккә җәлеп ителгән 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшьләр өлеше әлеге яшь төркеменең гомуми санынnan кимендә 5% | | | | - | 3% | 4% | 5% | 2025-2027 еллар | - | - | - | - |
| 1. | Совет гаскәрләрен Әфганстан Республикасыннан чыгару көненә багышланган тантаналы чара | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе (алга таба – яшьләр белән эшләү идарәсе) | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 70 | 80 | 100 | 2025-2027 еллар | - | 22,9 | 22,9 | 22,9 |
| 2. | Ватанны саклаучылар көненә багышланган тантаналы чара | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 150 | 170 | 200 | 2025-2027 еллар | - | 28,4 | 28,4 | 28,4 |
| 3. | Россия гвардиясе көненә багышланган тантаналы чара | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 50 | 70 | 90 | 2025-2027 еллар | - | 13 | 13 | 13 |
| 4. | Чик сакчылары көненә | Яшьләр белән | Чарада катнашучылар | - | 70 | 90 | 110 | 2025-2027 | - | 17,4 | 17,4 | 17,4 |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | багышланган тантаналы чара | эшләү идарәсе | саны, кеше | | | | | еллар | | | | |
| 5. | Хәтер һәм кайгы көненә багышланган истәлекле чара | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 90 | 100 | 110 | 2025-2027 еллар | - | 13 | 13 | 13 |
| 6. | Хәрби-диңгез флоты көненә багышланган тантаналы чара | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 100 | 110 | 120 | 2025-2027 еллар | - | 22,9 | 22,9 | 22,9 |
| 7. | Һава-десант гаскәрләре көненә багышланган тантаналы чара | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 100 | 110 | 120 | 2025-2027 еллар | - | 22,9 | 22,9 | 22,9 |
| 8. | Мотоукчы гаскәрләре көненә багышланган тантаналы чара | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 10 | 20 | 30 | 2025-2027 еллар | - | 11,9 | 11,9 | 11,9 |
| 9. | Танкистлар көненә багышланган тантаналы чара | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 10 | 20 | 30 | 2025-2027 еллар | - | 13 | 13 | 13 |
| 10. | Халыклар бердәмлеге көненә багышланган тантаналы чара | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 100 | 110 | 120 | 2025-2027 еллар | - | 24,6 | 24,6 | 24,6 |
| 11. | Ватан геройлары көненә багышланган тантаналы чара | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 50 | 60 | 70 | 2025-2027 еллар | - | 11,9 | 11,9 | 11,9 |
| 12. | Билгесез солдат көненә багышланган истәлекле чара | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Чарада катнашучылар саны, кеше | - | 60 | 70 | 80 | 2025-2027 еллар | - | 11,9 | 11,9 | 11,9 |
| | | | | | | | | Барлыгы: | | 213,8 | 213,8 | 213,8 |

«2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү» муниципаль программасына
2 нче кушымта

## Программа чаралары

| № т/б | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Программа чараларын башкаручылар – Башкарма комитетның структур бүлекчәләре | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|
| Тормышка ашырыла торган патриотик проектлар, чаралар саны | | | яшьләр белән эшләү идарәсе;<br>мәгариф идарәсе;<br>мәдәният идарәсе;<br>физик культура һәм спорт идарәсе | Программаны тормышка ашыру срогы дәвамында ел саен планлаштырылган күрсәткеч – узган ел белән чагыштырганда үсеш кимендә 3 % |
| 1. | Яр Чаллы шәһәрендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча Координацион совет төзү | Финанслау каралмаган,<br>чара оештыру характерына ия | яшьләр белән эшләү идарәсе | Составына Шәһәр Советы депутатлары, ведомство идарәләре һәм учреждениеләре, коммерцияле булмаган оешмалар вәкилләре кертелгән Координацион совет төзелде |
| 2. | Яшьләр өчен патриотик чараларның ведомствоара планын раслау | Финанслау каралмаган,<br>чара оештыру характерына ия | яшьләр белән эшләү идарәсе;<br>мәгариф идарәсе;<br>мәдәният идарәсе;<br>физик культура һәм спорт идарәсе | Ведомствоара план нигезендә кимендә 30 чара үткәрү |
| 3. | Патриотик чараларны яктырту өчен шәһәр массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итү | Финанслау каралмаган,<br>чара оештыру характерына ия | мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | Ел саен шәһәрнең рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында кимендә 20 басма |
| 4. | Яшьләргә патриотик тәрбия бирү өлкәсендә эшләүче белгечләр өчен методик семинарлар, укыту курслары оештыру һәм үткәрү | Финанслау каралмаган,<br>чара оештыру характерына ия | мәгариф идарәсе | Кимендә 250 белгеч катнашында кимендә 9 чара үткәрелде |
| 5. | Эшчәнлек юнәлеше нигезендә массакүләм патриотик шәһәр, республика, бөтенроссия чараларында хәрби-патриотик клублар әгъзаларының, «Юнармия» активистларының катнашуын тәэмин итү | Финанслау каралмаган,<br>чара оештыру характерына ия | яшьләр белән эшләү идарәсе;<br>мәгариф идарәсе;<br>мәдәният идарәсе;<br>физик культура һәм спорт идарәсе | Массакүләм патриотик шәһәр, республика, бөтенроссия чараларында катнашу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6. | Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының тарихи вакыйгаларына һәм истәлекле даталарына багышланган чаралар үткәрү (тематик күргәзмәләр, кинофестивальләр, тамашачылар белән тематик очрашулар, фестивальләр һәм башкаларны оештыру) | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | мәдәният идарәсе | Яшьләр мохитендә илебез тарихын һәм мәдәниятен популярлаштыру |
| 7. | Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерүгә һәм алар кылган батырлыкларга багышланган иң яхшы музейга (музей экспозициясенә) конкурс үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | мәдәният идарәсе | Яшьләрдә Россия һәм аның халыклары өчен традицион булган мәдәниятка нигезләнгән рухи-әхлакый кыйммәтләр һәм сыйфатлар формалаштыру |
| 8. | Яшьләр өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары оештыру, спортның хәрби-гамәли төрләрен пропагандалау | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | физик культура һәм спорт идарәсе | Яшүсмерләр һәм яшьләр өчен спорт объектларыннан максималь дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү.<br>Хәрби хезмәткә чакырылучыларның спорт разрядларын арттыру |
| 9. | Укучыларда патриотик аң формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | мәгариф идарәсе | Аңлы рәвештә үз иленең, республикасының тормышы һәм үсеше белән кызыксынган, җитлеккән гражданлык үзаңы булган шәхес формалаштыру |
| 10. | Урта гомуми белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларында укучыларны хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләүне оештыру һәм үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | мәгариф идарәсе | Хәрби белгечлекләр белән кызыксынуны үстерү; конституцион бурычларны үтәүгә әзерлек; барлык дәрәҗәдәге уку йортларының хәрби хәрәкәтләр ветераннары һәм кораллы конфликтлар оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге системасын җайга салу |
| 11. | Яшьләр өчен патриотик юнәлешле чаралар оештыру һәм үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | яшьләр белән эшләү идарәсе | Патриотик компонентны яшьләр тормышының барлык әһәмиятле өлкәләренә интеграцияләү.<br>Яшьләрдә хәрби хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру һәм аның абруен күтәрү |
| 12. | Яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең «Юнармия» һәм «Форпост» отрядлары эшчәнлеген активлаштыруда катнашуын тәэмин итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | мәгариф идарәсе, яшьләр белән эшләү идарәсе | Гомуми белем бирү, урта һөнәри белем бирү һәм югары һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларында укучыларның гомуми санынннан яшьләр иҗтимагый патриотик хәрәкәтләрендә катнашучыларның кимендә 5 % |